# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# «ТҮБӘН СУЫКСУ» АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

« 22 » ноябрь 2021 ел № 9/1

**«Түбән Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 22 августындагы вн.2/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 5, 394 һәм 397 статьялары, «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Түбән Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. «Түбән Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 22 августындагы вн.2/3 номерлы карарына (2017 елның 28 декабрендәге вн.3/2 номерлы, 2018 елның 10 сентябрендәге 8/5 номерлы, 2018 елның 25 октябрендәге 9/1 номерлы, 2019 елның 8 ноябрендәге 10/1 номерлы, 2020 елның 27 февралендәге 2/1 номерлы, 2021 елның 2 апрелендәге 2/1 номерлы, 2021 елның 6 июлендәге 6/2 номерлы карарлар үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктка пуктча өстәргә:

«11) «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатында, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан вәкаләт бирелгән махсус оешмалар милкендә булган җир кишәрлекләренә карата 0,001.».

2. Әлеге карарның 1 пункты 1.1 пункты рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «Түбән Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.Г. Ихсанов